СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

31 июль, 1998 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 86 (8243) | Бәясе билгеләнгәнчә

## ЭШЛӘРНЕҢ БАРЫСЫ ДА АШЫГЫЧ ЧАК

### Урак батырсыз узмас

**"Сөлчә"** хуҗалыгыннан **Александр Михайлович ЗАЙЧИКОВ** ЖРБлы "Нива" белән арыш уруда смена нормасын 140 процентка үти.

***

**"Заветы Ильича"дан Владимир Михайлович ИСАЕВ** бу кызу көннәрдә терлек азыгы хәзерләүдә сынатмый - КСК чапкычы белән 285 гектарда азык катнашмаларын эш ит-

***

**Синдряков исемендәге** хуҗалыктан **Павел Иванович ВАРЛАМОВ** бүген дә хуҗалыкта алдынгылыкны үз кулында тота - суктырган ашлыгы 1400 центнерлап булды инде.

### ТИЗ ТОТТЫЛАР

Бу көннәрдә "Рассвет" КХАсының 60 гектарлы борчак кыры гөрләп торды. Комбайннар тавышы, тракторчылар сөйләшүе иртә таңнан башлап кара төнгәчә тынмады: игенчеләр беренче сабан культурасын тиз дә, югалтуларсыз да җыюны максат итеп эшләделәр.

Рассветлыларны эшкә өйрәтәсеме соң?! Быелгы тансык икмәкне иң кадерле, иң дәрәҗәле ризык итеп җыеп баралар алар. Әнә Василий Семакаев белән Фәнис Төхфәтуллин комбайннары нинди җитез, тоткарлыксыз эшләделәр, Нурвахит Маняпов шул ук темптан калышмады. Елына күрә өлгергән борчактан 752 центнер уңыш җыйдылар алар, бу эшне бик кыска срокта башкардылар.

Гадәттәгечә, рассветлылар басуда эшне комплекслы оештырдылар. Ашлык җыелган басуларга шунда ук Касыйм Сатдаров һәм Наил Бикиев тракторлары керде. Егетләр кырларны саламнан чистарттылар. Быел терлек азыгы күпме әзерләнсә дә артык буласы түгел. Шуңа борчак саламын берьеллык үлән белән сенажга салдылар.

Шулай акрынлап урак көч җыя "Рассвет"та. Игенчеләр башка сабан культураларының өлгерүен дә шундый әзерлек белән көтәләр.

**С.НУРУЛЛИНА.**

### СЕНАЖ САЛЫНА

Быелгы корылык терлекләргә мул азык әзерләүдә проблема тудырса да, хафизовлылар кышкылыкка азыкны җитәрлек әзерләргә тырышалар. Алар тырышлыгы белән барлыгы 4000 центнер печән җыелып эскертләргә өелде. Бүгенге көндә азык әзерләүчеләр бөтен көчне сенаж салуга юнәлтәләр. Кырда Иван Мортазин һәм Евгений Черновның ике "Полесье"сы эшли. Алардан барлыгы 630 тонна азык ташылып базга салынды.

**С.ФӘЙЗУЛЛИНА.**

*Сара Бакирова. "Кондырча" КХАсының уңган савучысы соңгы елларда район савучылары ярышында алдынгылыкны бирми. Ике ел рәттән инде аңа район сабан туе әләмен күтәрү бәхете дә насыйп булды. Быел бу дәрәҗәгә ул районда иң зур көнлек савымны тәэмин итүе нәтиҗәсендә дә иреште: җәйге көннәрдә Сара апа группасында маллар 25әр кг. сөт бирәләр. Аның ел башыннан 5 айда сауган сөте дә хуҗалыкта иң күбе: 2865 килограмм. Икенче кат бозаулаган таналар белән эшләп, аларны мул сөтле сыерлар итү өчен көчен кызганмый савучы. Шуңа да аның группасында һәрчак күрсәткечәр югары була.*

*Рәсемдә: "Кондырча" КХАсы савучысы С.Бакирова.*



Н.АЗИЗОВ фотосы.

## АКЧАНЫ МАКСАТЧАН ТОТАРГА!


**Дәүләт финансын яхшырту максатында Татарстан хөкүмәте кайбер чаралар күрүне кирәк таба. Министрлыклар, дәүләт комитетлары, ведомстволар, кайбер идарәләр эшен тикшергәндә бюджет акчаларының тиешсезгә исраф булуы фаш ителде. Министрлар Кабинеты кабул иткән яңа карар нигезендә бу эштә гаепле затларга карата катгый чаралар күреләчәк. Республика бюджетыннан турыдан - туры файдаланучылар, бюджет акчасын урынлы тотмаучы җаваплы затлар матди зыянны 10нан алып 100 минималь окладка кадәр түләргә тартылачак. Бу гөнаһ кабатланган очракта эш урыныннан азат ителәчәкләр. Шәһәрләрнең һәм районнарның хакимият башлыклары республика бюджетыннан бүленгән акча тотылышына: бюджет акчасының хезмәт хакына, пенсиягә бирелүе өчен шәхсән җаваплы. Тиешсез гамәл булган очракта Министрлар Кабинеты бу затларны җавапка тарту турында Президентка тәкъдим кертү мөмкинлеген үзендә калдыра. Дәүләткә бурычлы предприятиеләргә 1998 елның 1 августына кадәр Татарстаннан читтәге банклар белән исәп - хисап ясап бетерергә тәкъдим ителде. Калган акчаны исә үзебездәге банкларга күчереп бетерергә кушылды. Әгәр бу таләпләр үтәлмәсә, йә бозылса, дәүләт салым инспекциясенә әлеге счет белән гамәлләрне туктату хокукы бирелә. Татарстан дәүләт салым инспекциясенә һәм РФның Татарстандагы Пенсия фонды бүлегенә Икътисад һәм сәнәгать министрлыгы белән берлектә, предприятие, оешмаларга счетлар ачу өчен таныклык бирү тәкъдим ителде.**

**Хезмәт хакы бирүдә, салым түләүдә һәм бюджетка бурычы булмаган предприятиеләр генә төрле дәгъва белдерә ала.**

**("Татар - Информ").**

** ТЕЛЕЖУРНАЛИСТЛАР ЭЗЕННӘН*

## "ЗӘҢГӘР ЭКРАН"ДА - НУРЛАТ ТОРМЫШЫ



**Узган атнада Татарстан телекомпаниясе журналистлары, безнең районның социаль - мәдәни тормышы белән танышып, күп кенә видеоязмалар төшереп киттеләр. Районыбыздагы кайсы тармаклар аларның игътибарын җәлеп иткән соң?**

### ҮЗӘК КИТАПХАНӘ

Монда китап укучыларның "Юникс" интеллектуаль - экологик клубы эшли. Клубның оештырылганына әле бер генә ел булса да, күзгә күренерлек эшләре, үз юнәлешләре, республика күләмендәге үз тиңдәшләре арасында үз йөзләре бар икән инде аларның. Нигездә шәһәр мәктәпләренең югары класс укучылары яратып шөгыльләнә торган бу клуб белән укытучылар да тыгыз элемтәдә яшиләр. "Юникс"ка йөрүче яшьләрнең "Чәчәкләр - минем нәфис дусларым" дигән әдәби уен - бәйгесен тележурналистлар да кызыксынып карадылар.

### "ЗАРЕЧНЫЙ" ЛАГЕРЕ

Кем генә килсә дә, мондагы тәртипкә, чисталыкка, оешканлыкка сокланып китә иде. Ә бу көнне баручыларга "Нептун" бәйрәмендә үзләренә дә катнашырга насыйп булган икән. Су патшасының туган көненә килеп эләккәч, дәрәҗәне - вазифаны, каян килүеңне һәм, гомумән, дөньяңны онытып суга чумарга да, җырларга һәм биергә дә, ярышырга да туры килде кунакларга.

### ШӘҺӘРНЕҢ 4нче МӘКТӘБЕ

- Республиканың шәһәр мәктәпләре арасында үзенең гектар ярымлы бакчасын һәм теплицасын булдырып, шуннан алган уңыш белән үзләрен генә тәэмин итеп түгел, башкаларга да өлеш чыгарырлык итеп эшләүче, балаларның сәламәтлеген ныгыту хакына заманча җиһазланган шифаханәсе эшләп торган ял лагере булган мәктәпне, һәм, әлбәттә, урта мәктәп язмышын аталарча кайгыртуны үз өстенә алган сезнең НГДУ кебек шефларны күргәнебез юк иде әле,- диештеләр тележурналистлар. Чынлап та, монда шефлар ярдәме белән мәктәпне яңа уку елына әзерләү, ел әйләнә уңыш үстерү өчен кышкы теплица булдыру, мәктәпнең эчке бизәлешен башкарып чыгу һ.б. эшләрне төгәлләп киләләр.

### ЯШЬЛӘР ЙОРТЫ

Балалар һәм яшьләр өчен тематик дискотекалар үткәрү монда җәйге чорда аеруча киң колач алды.

### ЮГАРЫ НУРЛАТ

Мәктәп янындагы тәҗрибә участогы бик уңганнарны да сокландырырлык. Бакчаның пөхтәлегенә һәм уңышка бай булуына үзләренең тырышлыгы сәбәпче икәнлеген һәр бала җаны - тәне белән аңлап эшли.

Балалар бакчасы исә шушы мәктәп өчен "затлы үсентеләр"не әзерләүче җирлек - чыганак булып тора.

### "ЯШЬЛЕК" КАФЕСЫ

Бу бинада туйлар һәм башка төрле тантаналар еш үткәрелә. Андый купшы бәйрәмнәр генә түгел, түгәрәк өстәл артында җитди сөйләшүләр оештырырга да бик кулай урын ул үзе. Югары классларда укучыларның "Гаиләдә аек яшәү рәвеше" дигән темага районның табиб - наркологы С.И.Федотов белән очрашуында катнашкан Казан журналистлары да шушы фикерне белдерделәр.

### МАМЫК

Урта Азия якларыннан кайткан качаклар өчен төзелгән торак йортлар да игътибардан читтә калмады.

Кунаклар "Зүзәйнефть" промыселындагы сәнәгать яңалыклары белән дә таныштылар.

### ӘЛМӘТ

Авыл мәдәният йортында район хакимиятенең яшьләр белән эшләү бүлеге оештырган зирәкләр, тапкырлар клубының чираттагы уен - тамашасы да бик кызык булды

### НУРЛАТ СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕ

Төзүчеләр быелның 15 августларына мондагы мәшәкатьләрне төгәлләү һәм мәктәпне ачу тантанасын күрү теләге белән яналар.

### "ЧИШМӘКӘЙ" МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

Бу эссе көннәрдә, әти - әниләре ах - вах килеп эшләп йөргән бер вакытта, "Чишмәкәй"гә йөрүче балалар кече сабан туенда көч сынаштылар, бәйрәм иттеләр. Уеннарның кызган мәлендә генә видеокамералар күтәреп чит - ят кешеләр килеп керүе дә аларны бер дә каушатмады.

### АГИТПОЕЗДГА УТЫРЫП

Бу көнне агитпоезд Муса Җәлил исемендәге КХА игенчеләре һәм терлекчеләре янына юнәлде. Телевидение вәкилләре дә алардан калышмады.

### "КИЕКЛЕ" КХАсы

Кунаклар бу көнне мул уңыш вәгъдә итүче чөгендер басуларын иңләп кайткач, яңа технология буенча, озак сакланышлы сөт җитештерү цехы төзелешен дә карадылар.

**"Нурлат тормышын "зәңгәр экран"нан карарсыз. "Чулпан" һәм "ТОН" тапшырулары бу хакта бер генә кат сөйләмәс әле!" - диделәр алар.**

**БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ**

***Татарстан Фәннәр Академиясе Тарих институтының археологик тикшеренүләр милли үзәге фәнни хезмәткәрләре майның икенче яртысында безнең Кизләү авылында һәм аның тирә - ягында эзләнүләр үткәргәннәр иде. Экспедициянең гамәли нәтиҗәләре хакында алар институтның башка тарихчы галимнәре каршында да исәп - хисап тотканнар, һәм милли үзәк бердәм карарга килгән.***

# МОНДАДЫР БЕЗНЕҢ БАБАЙЛАР ХУРЛАРЫ - ОҖМАХЛАРЫ...

## ТАРИХЧЫЛАР КИЛГӘН БЕЗГӘ...

**Килүчеләр икәү иде: берсе - археологик тикшеренүләр милли үзәгенең фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты - Айрат Марат улы ГОБӘЙДУЛЛИН, икенчесе - шул ук үзәкнең кече фәнни хезмәткәре Илгизәр Равил улы ГАЗЫЙМҖАНОВ.**



***Районыбызга археологлар килү узган еллардан бирле әледән - әле кузгалып торган Кизләү авылы юбилеена бәйле рәвештә башта безнең хакимият башлыгы Ф.С.Сибагатуллин тарафыннан, ә аннан шуның дәвамы буларак үз чиратында ФА Тарих институты директоры Р.С.Хәкимов ягыннан тизләтелгән булып чыкты. Бу экспедициянең төп максаты исә Кизләүнең борынгылык дәрәҗәсен билгеләргә ярдәм итүче археологик истәлекләр эзләү, ягъни казу эшләре алып бару - бармауның никадәр зарур булуын ачыклау иде.***

*Галим егетләрнең килүе авыл тормышына үзгәлек кертеп җибәрде, күз күнеккән гадәти күренешләргә бөтенләй башкача караш тудырды. Хәер, бу беренче генә дулкын түгел иде. Нәкъ шундый ук дулкынланып алу беренче тапкыр бу төбәктә 1963 - 65 елларда археолог, тарихчы - галим Р.Г.Фәхретдинов килгәч булса, икенчесе 1985 елда Әнвәр Хәйри борынгы кабер ташына юлыккач булды. Ә инде бу юлы килүчеләрнең ниятләре тагын да максатчан һәм ачык иде.*

*Бу төбәктә эшләү галим егетләрнең үзләре өчен дә гадәти экспедиция түгел. Чөнки Кизләүдә моннан 69 ел элек укытучы Халиковлар гаиләсендә Альфред исемле малай дөньяга килгән. Ә ул - бүгенгесе көндә татарның күренекле археологы һәм тарихчысы, татар халкы һәм Урта Идел буеның борынгы тарихы буенча дистәләгән фәнни монографияләр авторы, тарих фәннәре докторы, профессор, Татарстан ФА әгъза - корреспонденты, ТР Дәүләт премиясе лауреаты Альфред Хәсән улы Халиков. Әгәр исән булса, 1999 елның 30 маенда аңа 70 яшь тулар иде. Кызганычка каршы, 1994 елның көзендә ул дөнья куйды. Үзе исән вакытта олуг галимгә туган авылы төбәгендә фәнни тикшеренүләр алып бару насыйп булмаган шул. Ә хәзер менә аның эшен дәвам итүче яшьләр шушы туфракка кайтып баш игәннәр...*

*Фәнни эзләнүләр авыл белән танышудан башланды. Авыл кешеләренең бәрәңге бакчалары да алар өчен эзләнү мәйданына әверелде. Хәер, экспедиция эшләгән көннәрдә авылның олысы - кечесе дә үз теләге белән тартылды бу эшкә. Күңелдә ымсыну - сорау тудырган һәрбер таш, чүлмәк китеген алар археологларга алып килделәр. Ә инде егетләрнең бу табылдыкларга бәяләмәсе, аларның борынгы чор белән бәйләнешен тасвирлап бирүе һәркайсы өчен үзе бер ачыш булды.*

## АРХЕОЛОГЛАР ФАРАЗЫ

Без бу 10 көн дәвамында авылның бүгенге биләмәләрендә һәм аның якын - тирәсендә барысы 20дән артык борынгы истәлекне өйрәндек. (Аларның унлабы элекке экспедицияләрдә табылган иде, ә калган өлешен табу безгә насыйп булды.) Табылдыкларның тугызы бронза чорына (безнең эрага кадәрге ике меңенче еллар уртасына) карый һәм алар бура культурасына бәйле дип фараз ителде. Бура культурасы кабиләләре бу якка урнашкан беренче җирле кешеләр булганнар һәм алар беренчеләрдән булып шушы урыннарда терлекчелек һәм игенчелек белән шөгыльләнә башлаганнар. Зур Чирмешән, Сөлчә, Кондырча елгаларының тугайларында көтүлекләр һәм уңдырышлы җирләр күп булу аларны шушында тарткан. Әлеге төпләнү урыннарының берсе авылның көньяк - көнчыгыш читендә табылды. Кизләүдә яшәүче Хаҗиәхмәт Дәүләтшин бакчасында исә кызыл балчыктан әвәләп ясалган савыт- саба ватыклары (керамика) табып алдык. Бу савытларга төшерелгән бизәкләргә карап аларны бура культурасына хас керамика диярга ныклы нигез бар.



Безнең эрага кадәр XIII гасыр азагында әлеге кабиләләр ни сәбәпледер бу якларны ташлап китәләр. Һәм шуннан соң монда озак вакытлар буена - безнең эраның беренче мең еллыгы урталарына кадәр кеше яшәми. Бу яклардан сирәк кенә әүвәлге тимер гасырының күчмә халыклары узып китәләр. Әмма аларның тупланып яшәве турында Кизләү тирәсендә дәлилләр табылмады. Бу тирәләргә халыкның чагыштырмача урнашуы безнең эраның беренче меңьеллыгы урталарына туры килгән һәм алар имән кискә кабиләләре вәкилләре булганнар. Кизләү тирәсендә һәм аңа якын җирләрдә табылган 8 авыл урыны нәкъ менә имән кискәлеләрнеке дип фаразлана.

VII гасыр ахырында бу халык әлеге урыннарны янә дә ташлап китә. Имән кискәлеләрнең бер өлеше шушы якларда калып, Идел буе Болгар дәүләте халкының этник составына катнашкан булуы да бик мөмкин.

Болгар кабиләләре ярымкүчмә - ярымутрак тормыш алып барганнар. Аларның Урта Идел буена килеп урнаша башлавы VIII йөз урталарына туры килә. Сезонлы тукталу җирләрендә әкренләп киләчәктә авыл һәм шәһәрләргә әвереләчәк яшәү урыннары төзелә башлый. Бу урыннарның археологик калдыкларын тиз генә табып булмый. Кызганычка каршы, Кизләү авылы тирәсендә дә без андый табылдыкка юлыкмадык. Әмма Төрнәс авылы янында табылган истәлекләр бу төбәкнең күчмә болгар кабиләләре тереклек иткән зонага керүен дәлилли. 1963 елда Төрнәстә борынгы болгар керамикасы (кызыл балчыктан ясалган савыт - саба) үрнәкләре табылган булган.

Керамика дигәннән, аларның төсе товарның сыйфатын һәм җитештерү технологиясенең дәрәҗәсен күрсәтеп тора. Кизләү тирәсендә табылган савыт кисәкләре дә берничә чорга бүлеп карала. Әйтик, кызыл керамиканы җитештерү технологиясе -Кара диңгез һәм Азов буеннан килгән мирас. Бу төр товарны урыслар бик яратып сатып ала торган булганнар.

IX һәм X гасыр чикләрендә үзәкләштерелгән борынгы феодал дәүләт - Идел буе Болгар дәүләте формалаша. Болгарлар бу вакытка тулысынча диярлек утрак тормышка күчәләр. Шәһәрләр төзиләр, һөнәрчелек һәм сәүдә үсә, күрше фин, угор, төрки кабиләләр белән актив элемтә тоталар. Дәүләт дине булып ислам кабул ителә һәм X гасыр ахырына болгар җәмгыятенең барлык катламнарына үтеп керә. Игенчелек һәм терлекчелек гади халык өчен тормыш нигезе булып тора.Уңдырышлы җирләр һәм көтүлекләр эзләп алар Идел алды һәм Кама артындагы үзәннәргә килеп урнашалар.Безнең гасырның 60нчы елларында Кизләү янында табылган болгар авылы урыны нәкъ менә шул чорга карый. Җирле халык бу урынны "Иске авыл" дип йөртә. Һәм бүгенге Кизләү авылына шушы борынгы яшәү урыныннан күченеп утыручылар нигез салган дип исәпләнә.Зур Чирмешән елгасының уң як ярында (Нурлат - Әлмәт шәһәре шоссе юлының ике ягы буйлап) урнашкан әлеге авыл территориясендә кызыл балчыктан кул белән ясалган чүлмәк кисәкләре - монгол явына кадәрге чор истәлекләре җыеп алынды. Әлеге борынгы авылның яшәү вакытын тагын да төгәлрәк билгеләү өчен янә дә өстәмә экспедиция кирәк.

1236 елның көзендә Идел буе Болгар дәүләте монгол армиясе тарафыннан тар - мар ителә һәм аның шуннан соңгы тарихы турыдан - туры Алтын Урда тарихы белән бәйле.Кама аръягының кешесез калган җирләре XIII гасыр ахырына таба янәдән җанлана башлый.Үзбәк хан һәм а[illegible] варислары идарә и[illegible] чор Алтын Урданың чәчәк аткан еллары дип исәпләнә.Бу бәяләү элеккеге Идел буе Болгар дәүләте җирләренә дә туры килә.Нурлат районы территориясендә дә шушы чорга караган дистәдән артык археологик истәлек билгеле. Кизләү авылында да бар алар. Әйтик, 1985 елда бүгенге авыл зиратының көнчыгыш өлешендә Әнвәр Хәйри ( ул бу вакытта ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих институты фәнни хезмәткәре булган) тарафыннан табылган кабер ташы - ш[illegible]ның мисалы. Бу таш[illegible] "1304 (1314) ел" дип язылган. Ә инде авылның үзәк өлешен тикшергәндә, бигрәк тә урта мәктәп (элекке мәдрәсә) бинасы тирәсендә шушы чорга хас булган, кызыл балчыктан ясалган керамикадан коллекция тупланды. Ягъни бу керамиканың яшәеш дәвере кабер ташындагы еллар белән бер вакытка туры килә. Алтын Урда чорының балчыктан ясалган савыт -сабасы үзенең җитештерелү традицияләрендә элгәре эпоханың кайбер сыйфатларын (төс, форма, бизәкләү рәвеше һ.б.) саклый. Шул ук вакытта монгол явына кадәрге савыт - сабага хас кайбер билгеләр (шомалык, ялтыравыклылык, кызыл балчыкның составы һ. б.) юкка чыга бара. Кизләү авылының үзәгендә тупланган табылдыклар коллекциясендә соңрак чорга - Казан ханлыгы һәм Рус дәүләте эпохасына караган керамика үрнәкләре дә бар дип исәплибез.

**( Ахыры 4 нче биттә).**

## Синдряков исемендәге хуҗалыкта

# Челнинка буенда җәйләү бар

Түбән Чаллы фермасы сыерлары җәйләрен Челнинка елгасы буена урнашкан җәйге лагерьларда үткәрәләр.

-Монда җайлы эшләргә, - диләр сыер савучы хатын - кызлар. Чынлап та, күпчелек эш механикалаштырылган, эш ике сменалы итеп оештырылган. Малларның сөтләрен дә арттырулары тагын да рухны күтәрә. Дөрес, быелгы эссе бу яктан комачаулады, билгеле. Шуңа карамастан, былтырның шул чоры белән чагыштырганда быелгы күрсәткечләр шактыйга артыграк. Хуҗалык җитәкчесе В.М.Әбдрәхимов малларның продуктлылыгын тотрыклы итү монда эшләүче һәр кешенең, аларның хезмәтен оештыручыларның тырышлыгы нәтиҗәсе дә дип исәпли. Бу җәһәттән хуҗалыкның терлекчелек тармагын җаны - тәне белән кайгыртып йөрүче зоотехник Людмила Георгиевна Григорьеваның роле зурлыгын әйтә ул.



Савучылар да уңган. Ирина Казанцева һәм Нина Мамонтова группасында мәсәлән,тулай савым 700 килограммнан артып киткән. Бу һәр савым сыерга 19ар килограмм туры килә. Надежда Мамонтова һәм Татьяна Короткина группасының күрсәткечләре дә алардан азга гына калыша. Көтүчеләр Сергей Макаров, Сергей Власов, Павел Макаров, Иван Мамонтов малларны үзвакытында кырга чыгаралар һәм иң мул азыклы җирләрдә йөртеп кайтаралар.

# Дуңгызчылык - иң төшемле тармак



Дуңгызчылык тармагы Синдряков исемендәге хуҗалыкта аерым игътибарда дисәк, һич арттыру булмас. Беренчедән, бу электән үк гадәткә кергән кәсеп булса, икенчедән, аларның агрофирма җитәкчелеге астында булуы да үз ролен уйнамый калмый. Агрофирма фермаларны яңабаштан ремонтларга, төзекләндерүгә, алдынгы технология буенча үстерү өчен корырга зур ярдәм күрсәтә. Әле күптән түгел агрофирма, "Татмясопром" холдинг компаниясе белгечләре тарафыннан шул темага семинар да үткәрелә биредә һәм анда алга таба да дуңгызларның абзарын җайлырак, уңайлырак итү өчен киләчәктә дә бу җәһәттән эш алып барылачагы турында әйтелә. Хәзергә дә дуңгызлар үстереп, симертү өчен бөтен шартлар да бар, ди хуҗалык җитәкчелеге Түбән Чаллы дуңгыз фермаларына килгәч. Азык әзерләү буенча цех эшли, анда ана дуңгызларга да ,балаларына да аерым - аерым азык пешерелә, терлекләр көненә биш тапкыр тукландырыла.

Терлекчегә хезмәт хакы бөтенләй өметсезгә калган бер вакытта җитәкчелек аларны кызыксындырып мул үрчем алуга ирешү юлларын эзли һәм таба да. Дуңгыз караучылар хезмәткә натуралата түләү - бер анадан туган дуңгызларның 6сыннан артканын үзләренә алу ысулын зур канәгатьлек белән кабул итәләр һәм үрчем дә сизелерлек арта. Мисал өчен,соңгы балалату чорында Түбән Чаллы дуңгызчылык фермасында беренчелекне Агафья Короткина һәм Юлия Михеева бригадасы алган. Аларга азыкны Юрий Попов ташып тора. Үз карамакларындагы 38 ана дуңгыздан алар 330 дуңгыз баласы алалар. Тапшырылганнан калган 11әр(һәркайсына) дуңгыз баласы үзләренә булачак. Әлбәттә, шундый керем алган терлекчеләр малларына туклыклы, сыйфатлы азык ашату һәм аларны үзвакытында каплату турында да өстән хәбәр килгәнче үзләре кайгыртачак.

Шундый нәтиҗәле түләү ысулын хуҗалык җитәкчесе киләчәктә терлекчелекнең башка тармакларына да кертергә ниятли.



Хуҗалыкта иртәгәге көнне дә кайгырталар. Ике фермада да эш кайный: хуҗалык исәбе белән быел икесенә дә тышкы ремонт ясала. "Түбәләр, ишекләр - һәркайсы яңадан булачак",- ди тәҗрибәле ферма мөдире С.К.Васильев. Шунда ук эчтә дә сыерларны яңа технология һәм экономияле ысуллар буенча асрауга тулы әзерлек бара.

**Ф.ЗЫЯТДИНОВА.**

**Рәсемнәрдә: сыер савучы Ирина Казанцева; дуңгыз караучылар Агафья Короткина һәм Юлия Михеева; фермаларда ремонт бара.**

**Н, АЗИЗОВ фотолары.**

# РАДИОНОКТАЛАРНЫ ТОРГЫЗЫРГА

Мәгълүм булганча, радиотапшыруларның гамәлдәге системасы халыкка гадәттән тыш хәлләр турында да хәбәр итеп тора. Ләкин соңгы елларда кайбер предприятие һәм оешма җитәкчеләре төрле сәбәпләр белән ведомствога буйсынулы предприятиеләрдә радионокталарны бетерү ягын карыйлар. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең, Татарстан Гражданлык оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының чыбыклы радиочелтәр аша тапшырыла торган мәгълүматын халыкка үзвакытында җиткерү өчен ТР Министрлар Кабинеты 394 номерлы карар кабул итте. Аның нигезендә оешма һәм предприятиеләр, милек формалары нинди булуга һәм кайсы ведомствога буйсынуларына карамастан, радионокталарны даими әзерлек хәлендә тотуны тәэмин итәргә тиешләр.

Җәмәгать урыннарында һәм кешеләр күпләп туплана торган урыннарда радиотапшырулар системасын бетерү ТР Гражданлык оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы рөхсәте белән генә башкарыла ала. Чыбыклы радиотапшырулар челтәрен инде бетерергә өлгергән урыннарда аны торгызу чараларын күрергә кирәк.

Промышленность һәм гражданлык объектлары, шулай ук торак йортлар бары тик локаль радиотапшырулар системасы булганда гына файдаланугa тапшырылачак.

## Газета · Укучы · Газета · Укучы

# ДУСЛЫК - "ДУСЛЫК"тан башлана, яки...

Фикер

Соңгы елларда "Дуслык" газетасының абруе күтәрелде дияр идем мин. Моннан берничә ел элек бастырылган газетаны чагыштыру да бик җитә. Хәрефләре яхшы басыла, зур һәм аңлаешлы. Укырга бик җиңел. Тик менә эчтәлеге генә әлегә бик мактанырлык түгел. Һаман колхоз да, кыр да, ферма... Максаты шулдыр инде "Дуслык"ның. Ә бит районда үткәрелеп килгән культура, спорт, сәнгать чаралары бик күп хәзер. Менә шунда булган проблемалар, күңелле күренешләр, тәрбия алымнары турында газетада мәкаләләр юк диярлек. Яшьләргә багышланган бер рубрика да юк. Әллә инде редакциядә бер генә дә яшь журналист юкмы?

Шунысын да әйтеп үтми булмас. "Дуслык" безне алдарга җыена бугай. Дөресрәге, абунәчеләр газетага язылганда ярты ел атнага өч сан алырбыз диеп уйлаганнар иде. Акча да шул исәптән түләнгәндер. Ә хәзер газетаның атнага ике генә калуы мине генә түгел, барлык абунәчеләрне дә уйга калдыра. Баш мөхәррир:"Полиграфия мөмкинлекләре чикләнү сәбәпле" дип 11 июль санында нәрсә әйтергә теләде икән?Бу хакта тиз арада җавап бирсәгез иде.

**Хәлим ӘЛИМОВ.**
**Яңа Иглай.**

***Редакциядән.***

***Яшь авторыбыз Хәлим Әлимовның хатын үзгәртмичә, тулысынча бирәбез, аның хатында күтәрелгәннәрнең ни дәрәҗәдә урынлы булуын укучыбыз үзе бәяләр. Шунысын гына әйтәбез: "Дуслык"ның 11 мең дана укучыларының яртысыннан артыгы - иген үстерүчеләр, ферма эшчеләре, авыл кешеләре. Шуңа да газета төп укучыларының мәнфәгатен һич кенә дә читләтеп үтәргә җыенмый һәм ул гадел дә булмас иде. Һәм, гомумән, газета нинди генә икътисадый - сәяси җилләр искәндә дә җитештерүчән хезмәт кешесен зурлауны беренче планга куя һәм шуның белән укучыларыбыз хөрмәтен саклый да. Ә менә мәдәният, мәгариф, тәрбия темалары күтәрелми дию белән Хәлим энекәш нык ялгыша, безнеңчә.Мөгаен, бу аның "Дуслык"ны даими укымавыннан киләдер. Инде яшьләр темасына язмаларны күбрәк күтәрергә теләсә, рәхим итеп безгә язып торсын - без аңа андый мөмкинлекне бирәбез, иң проблемалы мәсьәләләрне күтәрүенә өмет тотабыз.***

***Инде "Дуслык"ның график нигезендә чыга башлавын авторыбыз аңлагандыр. 66 ел нәшер ителү чорында газета үз укучылары алдында вәгъдәсез булмаган иде, хәзер дә абунәчеләрнең ышанычы безнең өчен бик кадерле. (Х.Әлимов ашыгыбрак гаепләргә алынган.) Шуңа редколлегия газетаны өзлексез чыгару өчен барлык мөмкинлекләрне эшкә җикте.***

# ТЕЛЕФОННАР ЧЫЛТЫРАМЫЙ...

Исәнме, кадерле редакция! Иске Әмзә авылыннан без. Апрельдән бирле телефоннарыбыз эшләми. Ничә тапкыр район элемтә узелына чыксак та, нәтиҗә юк: кабель алыштырасы, ул бик четрекле эш, диләр. Четрекле булгач, аны эшләмәскә дә микәнни? Безгә нәрсә эшләргә ди бу шартларда? Зинһар, үтенечебезне элемтә җитәкчеләренә җиткерергә булышыгыз.

**Авыл халкы исеменнән И.НӘБИУЛЛИН.**

# РӘХМӘТ АРТЫННАН РӘХМӘТ

**Бер игелек өчен рәхмәт белдерергә редакциягә өч кеше килде. Өчесе дә инвалидлар, исәннәр тарафыннан яхшы, җылы мөнәсәбәт күрү - алар өчен мәңге хәтердә саклана торган вакыйга.**

21 июль көнне сукырлар җәмгыятеннән 25ләп кешене утырткан автобус Биләр чишмәсенә таба юнәлә. Татар, рус, чуваш милләте кешеләре - һәркайсы сыя анда. Изге чишмә җиренә барып һәркем үзенчә догасын укый, гыйбадәт кыла, алып баручылар ярдәме белән кайберәүләр корбанга тавык чала, кайберәүләр алып барган ризыгын пешерә. Шулай ук кем якыннары, кем чит кеше булышлыгы белән югарыга таба баскычларны санап менү бәхетенә дә ирешә. Аннан алган җылы истәлекләр күңеле китек кешеләрнең йөрәгендә уелып кала.

Редакциягә килүчеләр, сукырлар җәмгыяте члены Р.П.Кислова, А.М.Җиһаншин, сукырлар җәмгыятендә групорг В.Е.Осипова Биләргә баруны оештыручыларга олы рәхмәтләрен җиткерәләр. Иң элек башлап йөрүче сукырлар җәмгыяте рәисе З.И.Богдановага, автобус биргән өчен АТП директоры И.М.Вәлиевка һәм рәхмәтләрнең иң олысы- игелекле җанлы автобус шоферы Әнвәр Галимовка. Чишмәгә алып барып кайту белән генә чикләнмичә, ул исәнсез кешеләргә тиешле урынга урнашуда, ризыкларын әзерләүдә дә олы ярдәм күрсәткән.

**Хатлар бүлеге.**

# МОНДАДЫР БЕЗНЕҢ БАБАЙЛАР ХУРЛАРЫ - ОҖМАХЛАРЫ ...

## АРХЕОЛОГЛАР ФАРАЗЫ

**(Ахыры.Башы 2 нче биттә).**

Шулай итеп, Кизләү һәм аның әйләнә - тирәсендә үткәрелгән археологик эзләнүләр бу авылның һәм тирә - юньнең бик борынгы тарихы булуын һәм аның безнең эрага кадәр ике меңенче елларга кадәр күзаллануын күрсәтте. Бүгенге Кизләү авылы Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорындагы авыл урынында утыра. Кизләү янәшәсендә бу чорга караган башка авыл калдыклары хәзергә мәгълүм түгел. Шуңа күрә, безнең фикеребезчә (һәм моны раслаучы археологик дәлилләр дә бар), болгар авылы ("Иске авыл") халкының бер өлеше монгол һөҗүменнән соң туган җирләренә әйләнеп кайткан һәм авылны таланган - яндырылган хәлдә күргәч, яңа урынга - бүгенге Кизләү урынына нигез корган булырга тиеш. (Халыкта бер ышану яши: янган йорт урынына яңаны салсаң - ул аның хуҗаларына игелек китерми, диләр. Шуңа күрә дә яңа йортны да, хәтта авылларны да яңа урында, һич югы элеккесеннән бераз читтәрәк төзергә тырышканнар.)

Кизләү тарихын җентекләп өйрәнү һәм фәнни нигезләнгән катгый нәтиҗәгә килү өчен казу эшләре башкару кирәк. Шуңа күрә без сентябрь аенда курган өемен (бура культурасы чорыннан калмаганмы?), имән кискә чоры авылының урынын, "Иске авыл" төбәген, "Иске зират"ны (Нурлат - Әлмәт олы юлы буйлап) һәм башка тагын берничә объектны казу эшен пла̀нлаштырабыз. Бу эзләнү нәтиҗәләре Кизләү өчен генә түгел, һичшиксез, гомумән тарихыбыз өчен дә кыйммәтле чыганак булыр дип өметләнәбез.

## ХУШЛАШКАНДА

егетләр болай диделәр:

- Сезнең район хакимиятенең халкыбыз тарихына, уртак мирасыбызга булган мөнәсәбәте бүгенге заманда безнең өчен үзе бер табылдык булды. Хезмәтебезне оештыруда башлангыч биргән, теләктәшлек күрсәткән һәм хәер - фатихада булган район җитәкчелегенә, ярдәмчел һәм кунакчыл Кизләү халкына олы рәхмәтебезне җиткерсәгез иде...

## Соңгы сүз

Археологик тикшеренүләр милли үзәгенең Кизләү юбилеен үткәрүне оештыру буенча вәкаләтле махсус комиссия төзүе, алдагы елда Халиков юбилеена туры китереп халыкара фәнни конференция уздырырга ниятләве һәм Кизләү урта мәктәбенә шәрәфле якташыбыз исемен бирү турындагы мәсьәләгә тукталуы шулай ук очраклы хәл түгел. Соңгы гасырларда мәгърифәт нуры буларак та танылган Кизләү төбәге турында Тукаебыз сүзләре белән "Мондадыр безнең бабайлар хурлары - оҗмахлары",- диясе килә.

**К.ҖАМАЛЕТДИНОВА.**
**Н. АЗИЗОВ фотолары.**

---

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Бикүле урта мәктәбендә эшләүче хезмәттәшебез **Роза Юныс кызы Миннекәева**ны 50 яшьлек юбилее белән тәбрик итәбез.

Һәлакәтләр сезне читләп үтсен,
Күңелләргә кайгы тулмасын.
Ходай сезгә озын гомер
бирсен,
Шатлыкларның чиге булмасын.

**Бикүле урта мәктәбе коллективы.**



АЛМАЛАР ӨЛГЕРӘ

**Р.ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ фотоэтюды.**

# БЕЛДЕРҮЛӘР

## УКЫРГА ЧАКЫРАБЫЗ

**Мәктәпләрдә һәм дини укыту - тәрбия учреждениеләрендә эшләү, ходай тәгаләнең чын динен саклау һәм үстерү максатыннан чыгып, Казандагы "Мөхәммәдия" югары мөселман мәдрәсәсенең Нурлат шәһәрендәге филиалы 1998 - 99 елда уку өчен шәкертләр кабул итә.**

**Мәдрәсәдә белгечләр хәзерләү көндезге уку рәвешендә алып барыла. Анда тулы урта белемгә ия, шулай ук тәмамланмаган урта белемле 15 яшьтән ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр бушлай туклану белән тәэмин ителәләр.**

**Бездә белем алучылар шәкерт статусына ия булалар. Укыту планы һәм программасының барлык таләпләрен үтәгән, чыгарылыш имтиханнарын уңышлы тапшырган шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.**

**Мәдрәсәдә укырга теләүчеләр 20 сентябрьгә Нурлат шәһәре, Комсомол урамындагы мәчеткә:**

**1. Гариза.**
**2. Белем турында таныклык.**
**3. Хәрби билет яки аны алыштырырлык таныклык.**
**4. Сәламәтлек турында белешмә тапшыралар.**

**Документлар кабул итү һәр атнаның пәнҗешәмбе - җомга көннәрендә 10 - 15 сәгатьләрдә үткәрелә.**

**Күңелләрен игелекле, изге теләк биләгән, ислам мәгърифәтен таратуга гомерләрен багышларга җыенган балаларны көтеп калабыз.**

**Укулар 1 октябрьдән башлана.**

**Мәдрәсә җитәкчеләре:**
**Ильяс хаҗи АМИШЕВ,**
**Әхтәм хәзрәт ТИМБИКОВ.**

## АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Яр Чаллыдагы ике бүлмәле фатирны - Нурлаттагыга, вариантлар мөмкин.**
Адрес: М.Җәлил ур., 9.

***

**Кормыш ягындагы өч бүлмәле фатирны - өстәмә түләп бер бүлмәлегә (икенче, өченче кат булса яхшы, шикәр заводыннан һәм тимер юлдан тәкъдим итмәскә).** Тел.: 5-16-42, кичке 6дан соң.

***

**Шәхси йортны - 2 һәм 1 бүлмәле фатирларга. Газ белән җылытыла, 8 сутый җире, газ кертелгән мунчасы, кирпеч гаражы, ике сарае, сууткәргече, канализациясе бар. Вариантлар мөмкин.** Тел.: 5-16-63, кичке 6нчы яртыдан соң.

## САТАМ

**Ашыгыч төстә 1 бүлмәле фатир.**
Тел.: 5-44-13.

## САТЫП АЛАМ

**Кулланылышта булган кухня гарнитуры.**
Арадашчы тел.: 5-28-22.




Кешенең баш мие көнгә 4 сәгать дәвамында гына яхшы эшли икән. Кешелек дөньясы бүген кирәгеннән артык эшли. Моның сәбәбе - электр лампасы уйлап табылу: шуның нәтиҗәсендә эш сәгатьләре артты, төнге сменалар килеп чыкты.

***

Төнлә 3 сәгатькә кимрәк йокласаң, иммун системасы какшый, кешенең реакциясе йомшара. Сталин ГУЛАГларында кешене йоклатмыйча газапланнар һәм бу - иң куркыныч, гомер кыскарта торган җәза булган. Балалар йокы туймаудан интегә. Балалар йоклаганда үсәләр, йокы туймаган бала сүлпән, чирләшкә була.

**("Мәдәни җомга"-дан).**

# БЕЛДЕРҮЛӘР.

## САТАБЫЗ

**"Игенче" КФХАсы халыкка, предприятиеләргә һәм оешмаларгаданәсен 4 сумнан 20 х 40 см.лы керамзит блоклар сата. Акчаны кулдан түләргә, бартер да мөмкин.**

**Мәрмәр кыйпылчыкларыннан 450 - 500 сумнан язулы, 800 - 1000 сумнан кара мәрмәргә ясалган портрет белән кабер ташлары сатам (эшләп бирү срогы 1 - 2 көн).** Адрес: Ленинград ур., 14.

***

**5 һәм 2 тапкыр бозаулаган ике сыер.** Бикколда Хасыйбулла Вәлиуллинга мөрәҗәгать итәргә, тел.: 2-33-66.

***

**Ашыгыч төстә "Москвич - 412", кыйммәт түгел.**
Тел.: 5-39-69.

***

**50 мм. диаметрлы сууткәргеч торбалар, 30 м.лы "рабица" челтәре.** Тел.: 5-35-81, теләсә кайчан.

***

**Азык - төлек комбинаты ягында базы белән капиталь гараж.** Тел.: 2-17-32.

***

**"Минск" мотоциклы.** Адрес: Циолковский ур., 44.

***

**Аз кешеле гаиләләләр йортында гомуми мәйданы 35,4 кв. метрлы бүлмә.** Арадашчы тел: 5-19-48.

***

**Әфган поселогында эчке эшләре эшләнмәгән ,төзелеп бетмәгән йорт, тирәсе тотып алынган, гаражы бар.** Тел.: 5-11-42 яки 2-24-12.

***

**Яңа "Термикс" газ казаны, бәясе килешү буенча.**
Адрес: Мәктәп ур., 13 - 3., кичке 5тән соң.

***

**1986 елгы әйбәт хәлдәге ВАЗ - 2121 "Нива".**
1 августта Богдашкино авылында Семен Жуковка мөрәҗәгать итәргә.

***

**1996 елгы, 41 мең км. юл үткән, ак төстәге бик әйбәт хәлдәге ВАЗ - 21093. Бәясе чамалы, өлешчә азык - төлек продуктлары белән дә түләргә мөмкин.**
Иске Чаллыда Николай Николаевич Захаровка мөрәҗәгать итәргә, тел.: 3-12-27.

***

**Азык - төлек комбинаты каршында базлы, тимер - бетон түбәле капиталь гараж.**
Адрес: Гыйматдинов ур., 51- 16, тел.: 2-24-66.

***

**Әфган поселогында нигезе белән участок, бетон коесы бар. Тел.: 5-39-52, 5-15-49.**

***

**Табагын 28 сумнан 1,70 х 2,75ле ДВП, табагын 40 сумнан 4мм.лы (1,30 х 1,60) пыяла, төргәген 55 сумнан рубероид, линолеум**. Тел.: 2-24-03.

***

**"Болгар" кибетендә барлык төр сөт продуктлары һәм ипи сатыла.** Адрес: "Яшьлек" кафесы, 1нче кат.

***

**1996 елгы ВАЗ - 21061, 547нче ПМК янында базы белән капиталь гараж.** Тел.: 5-38-40.

***

**40 мең км. йөргән ВАЗ - 21213, ЮМЗ - 6 тракторы, "ИФА - 25" йөк фургоны, "Газель" класслы дизель, вариантлар мөмкин.** Тел.: 2-26-95.

***

**1998 елның апрелендә чыккан ВАЗ - 21093.**
Тел.: 5-21-70.

***

**"Алмалык" бакчачылык ширкәтендә 6 сутыйлы дача участогы, йорты, коесы бар.**
Адрес: Дружба ур., 51 - 2, кичке 6дан соң.

**Керамзит блоклар, данәсе 3 сум. Димитровград шәһәрендә "Алиса" кибете артында элеккеге "Сельхозхимия" базасына мөрәҗәгать итәргә. Түләү формасы төрле, бартер мөмкин, китереп бирәбез.**
Тел.: (84235) 3-06-41

## ТӨРЛЕСЕННӘН

**2нче мәктәп тарафыннан Олег Николаевич Шарый исеменә бирелгән Б №547885 аттестатын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**Урта белем турында Яңа Иглай мәктәбе тарафыннан Гөлия Рөстәм кызы Гобәйдуллина исеменә бирелгән №694950 аттестатын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**

***

**ОСТОның Нурлат район Советы "В", "ВС", "ДЕ" категорияләренә шоферлыкка укучылар җыя.**
Тел.: 2-25-80.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА.**

Учредительләр: Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.
Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2337 данә. 3115